**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Иске Котыш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге составына керүче Красная Поляна торак пунктында

**22.10.2024 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең Красная Поляна торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм өлкәнрәк гражданнардан тыш.
2. Алынган чараларны җибәрергә:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (җәйге һәм кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, аларга хезмәт күрсәтү чыгымнары, юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, Красная Поляна торак пунктында кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу), халыкның массакүләм ялы өчен шартлар тудыру һәм Красная Поляна торак пунктында җәмәгать урыннарын төзекләндерүне оештыру).

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге башлыгы А.К.Митякин